| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.11.2014 Казан ш. № 8-1/соц

***«Даими яки вакытлыча стационар булмаган социаль хезмәтләндерүгә мохтаҗ булган өлкән яшьтәге һәм инвалид гражданнарны өйдә социаль хезмәтләндерү» дәүләти хезмәтләрен алучыларга гарантияле күрсәтелә торган социаль хезмәтләр исемлегенә керә торган социаль хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында***

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Бәяләрне (тарифларны) дәүләти көйләүне тәртипкә салу чаралары турындагы” 7.03.1995 ел № 239 карарына, Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасында халыкны социаль хезмәтләндерү турындагы” 13.11.2006 ел № 69-ЗРТ законына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Даими яки вакытлы стационар булмаган социаль хезмәтләндерүгә мохтаҗ булган өлкән яшьтәге һәм инвалид гражданнарны өйдә социаль хезмәтләндерү” дәүләт хезмәтенең сыйфат стандартын раслау турындагы” карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында кагыйдәләренә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР ИТӘ:

1. “Даими яки вакытлы стационар булмаган социаль хезмәтләндерүгә мохтаҗ булган өлкән яшьтәге һәм инвалид гражданнарны өйдә социаль хезмәтләндерү” дәүләти хезмәтен алучыларга бирелә торган гарантияле социаль хезмәтләр исемлегенә керүче социаль хезмәтләргә тарифларны шушы карарга кушымтага ярашлы рәвештә билгеләргә.

2. Шушы карар аны рәсми игълан итү көненнән соң ун көн үткәч үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифларбуенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан Республикасының
Тарифлар буенча дәүләт
комитетының 28.11.2014 № 8-1/соц
карарына кушымта

“Даими яки вакытлы стационар булмаган социаль хезмәтләндерүгә мохтаҗ булган өлкән яшьтәге һәм инвалид гражданнарны өйдә социаль хезмәтләндерү” дәүләти хезмәтен алучыларга бирелә торган гарантияле социаль хезмәтләр исемлегенә керүче социаль хезмәтләргә тарифлар

| Т. № | Социаль хезмәт атамасы | Хезмәт күрсәтүнең күләм характеристикасы | Хезмәт күрсәтүгә тариф, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Дәүләт хезмәтен алучы яшәгән районда урнашкан сәүдә оешмаларында азык-төлек сатып алу һәм аны өйгә китерү | 7 кг.га кадәр | 50,4 |
| 2. | Азык-төлекне әзерләүгә кадәрге эшләр (юу, эшкәртү, турау) | 1 блюдо | 32,8 |
| 3. | Ашамлык әзерләү | 1 блюдо | 66,2 |
| 4. | Ашамлыкны бирү һәм ашату | бер тапкыр ашату | 32,6 |
| 5. | Савыт-саба юу | ашарга әзерләүдән һәм (яисә) бер тапкыр ашатудан соң | 17,5 |
| 6. | Дәүләт хезмәтен алучы яшәгән райондагы җәяү бармалы сәүдә оешмаларында беренче кирәклек индустриаль товарларын сатып алу һәм өйгә китерү | 7 кг.га кадәр | 45,8 |
| 7. | Су китерү | 40 литр | 44,6 |
| 8. | Торак бинаны җылыту | | |
| 8.1. | Ягулык алуга заказ бирү һәм (яки) ягулык алу (агымдагы елның 1 октябренә кадәр) | заказ | 59,9 |
| 8.2. | Әзерләнгән ягулыкны саклау урыныннан мичкә китерү | заказ | 14,3 |
| 8.3. | Торак бинада мичкә ягу | заказ | 51,3 |
| 8.4. | Мунча мичен ягу | заказ | 117,9 |
| 9. | Чүп чыгару | чиләк | 11,7 |
| 10. | Сыек көнкүреш калдыкларын чыгару | чиләк | 19,5 |
| 11. | Әйберләрне юуга, химик чистартуга бирү | 7 кг.га кадәр | 67,3 |
| 12. | Кием-салымга вак ремонт | 1 операция | 27,0 |
| 13. | Торак бинага юл салу өчен йорт яны территориясен кардан чистарту | 10 кв. метр | 40,0 |
| 14. | Шәхси һәм гигиеник карау хезмәтләре: | | |
| 14.1. | душта, мунчада, ваннада юындыру | заказ | 87,5 |
| 14.2. | юеш сөлге белән сөртү | заказ | 27,4 |
| 14.3. | юындыру | заказ | 13,1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 14.4. | эчке киемен алыштыру | заказ | 27,2 |
| 14.5. | түшәген алыштыру | заказ | 31,6 |
| 14.6. | олылар өчен аскы чүпрәкләрне алыштыру | заказ | 40,2 |
| 14.7. | аскы чүпрәкләрне алыштыру, чүлмәк чыгару, аны юу, дезинфекция чаралары белән эшкәртү | заказ | 28,2 |
| 15. | Торак-коммуналь һәм башка шундый хезмәтләр өчен түләүгә квитанцияләр тутыру | заказ | 14,2 |
| 16. | Торак бина, коммуналь хезмәтләр, башка хезмәтләр өчен үз вакытында түләү | заказ | 42,5 |
| 17. | Мәдәният-күңел ачу чараларына билетлар алу һәм китерү | заказ | 58,3 |
| 18. | Өйгә вакытлы матбугат алдыру һәм китерү | заказ | 23,6 |
| 19. | Вакытлы матбугатка язылу | заказ | 45,9 |
| 20. | Көнкүреш техникасын ремонтлауга заказ бирү: | | |
| 20.1. | телефон буенча | заказ | 15,0 |
| 20.2. | ремонт хезмәте күрсәтүче оешмадан килү белән | заказ | 60,0 |
| 21. | Җибәрү, алу: | | |
| 21.1. | посылканы | 7 кг.га кадәр | 61,3 |
| 21.2. | почта бүлеге аша телеграмма я заказлы хатны яки почта яшнеге аша хатны | заказ | 34,0 |
| 22. | Хатлар язу, уку | заказ | 25,3 |
| 23. | Стационар социаль хезмәт оешмаларына юнәлтелүгә булышу | заказ | 100,5 |
| 24. | Клиент белән ул стационар саулык саклау оешмасында (муниципаль берәмлек чикләрендә) госпитализациядә чакта барып күрешү | заказ | 103,5 |
| 25. | Ритуаль хезмәтләрне оештыру (туганнары булмаганда) | заказ | Күмү буенча гарантияле хезмәтләр исемлегенең законнарга яраштырып расланган бәясе |
| 26. | Сатып алу һәм өйгә китерү: | | |
| 26.1. | рецепт яздырмыйча дару чараларын | заказ | 32,5 |
| 26.2. | алдан рецепт яздырып, шул исәптән җиңеллекле дару чараларын | заказ | 86,6 |
| 26.3. | медицина эшләнмәләрен | заказ | 33,0 |
| 27. | Өйгә врач чакырту | заказ | 12,4 |
| 28. | Врач-белгечкә кабулияткә яки диагностик тикшерүгә яздыру | заказ | 32,9 |
| 29. | Дәвалау оешмасына госпитализациягә юллама алу | юллама | 81,1 |
| 30. | Медина процедураларын үткәрү: | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 30.1. | мускулга я тире астына иньекцияләр ясату | 1 хезмәт | 28,3 |
| 30.2. | тән температурасын үлчәтү | 1 хезмәт | 6,1* |
| 30.3. | артерия басымын үлчәтү | 1 хезмәт | 9,1* |
| 30.4. | тиренең инфекцион чирләренә, оешыкларга визуаль контроль | 1 хезмәт | 12,6 |
| 30.5. | оешыкларны эшкәртү | 1 хезмәт | 43,7 |
| 31. | Саулыкка бәйле процедураларны үткәрүдә булышу: | | |
| 31.1. | тамызу | 1 хезмәт | 7,8 |
| 31.2. | сылау | 1 хезмәт | 12,0 |
| 31.3. | горчичниклар (яки банкалар, компресслар) кую | 1 хезмәт | 25,4 |
| 31.4. | физик күнекмәләр башкаруда булышу | 1 хезмәт | 32,3 |
| 32. | Лаборатор тикшерүләр өчен материаллар (сидек, тәрәт, селәгәй) алу һәм дәвалау оешмасына илтү | заказ (һәр атама буенча) | 53,8 |
| 33. | Санитар-гигиеник хезмәтләр: | | |
| 33.1. | тырнак кисү (кулларда, аякларда) | заказ | 36,8 |
| 33.2. | тарау | заказ | 12,8 |
| 34. | Медик-социаль экспертиза, социаль-медик характердагы реабилитация чаралары, врачлар нәтиҗәсе буенча санатор-курорт дәвасына юнәлтү, инвалидның шәхси реабилитация программасы, техник карау һәм реабилитация чаралары, теш протезлау, протезлау-ортопедия һәм ишетү протезы алу буенча ярдәм күрсәтү, шул исәптән: | | |
| 34.1. | консультация | заказ | 22,3 |
| 34.2. | медик һәм башка кирәкле документларны җыю һәм рәсмиләштерүдә булышу | заказ | 109,8 |
| 34.3. | Дәүләт хакимияте органына (оешмага, предприятиегә) гариза һәм (яки) документлар бирү | заказ | 60,1 |
| 35. | Клиентны социаль түләүләр, социаль хезмәт күрсәтүләр, социаль реабилитация, законда каралган җиңеллекләрне һәм өстенлекләрне алу буенча консультацияләү | һәр сорау төре буенча заказ | бушлай |
| 36. | Социаль түләүләр, социаль хезмәт күрсәтүләр, социаль реабилитация, законда каралган җиңеллекләрне һәм өстенлекләрне алу буенча дәүләт хакимияте органына (оешмага, предприятиегә) гариза һәм (яки) документлар бирү | һәр сорау төре буенча заказ | 78,7** |
| 37. | Социаль түләүләр, социаль хезмәт күрсәтүләр, социаль реабилитация, законда каралган җиңеллекләрне һәм өстенлекләрне алу белән бәйле мәсьәләләр буенча гаризалар һәм башка документлар төзүдә юридик ярдәм күрсәтү | заказ | 62,0** |
| 38. | Юридик консультациягә, нотариаль конторга яздыру | заказ | 25,0** |
| 39. | Өйдә нотариус, юрист хезмәтләре күрсәтүгә гариза бирү | заказ | 36,0** |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 40. | Законнарда каралган тәртиптә бушлай адвокат ярдәме бирүдә яки судта вәкиллек итүдә булышу | заказ | 81,0** |

<*> клиент теләсә нинди медицина процедураларына заказ биргәндә бушлай үтәлә
<**> законнарга ярашлы рәвештә бушлай юридик ярдәмгә хаклы гражданнардан тыш

Татарстан Республикасытарифларбуенча
Дәүләт комитеты, Тарифларбуенчакарарларны
кабул итү, оештурыһәмҗайга салу бүлеге